РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ТЕРРИТОРИАЛЬНАЯ ИЗБИРАТЕЛЬНАЯ КОМИССИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО РАЙОНА**

Ленина ул., д. 46, с. Тюлячи, 422080
тел. (факс): (84360) 2-14-34 16Т.048@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ**

Ленин ур., 46 нчы йорт, Теләче авылы, 422080
тел. (факс): (84360) 2-14-34 16Т.048@tatar.ru

# КАРАР

20 ноябрь 2017 ел № 270

## 2017 елның 19 ноябрендәге Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Шәдке авыл җирлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 56 статьясы нигезендә, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләре беркетмәләренең беренче нөсхәләре күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясе (ИКМО) тарафыннан 2017 елның 19 ноябрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзеде, аның нигезендә:

Тавыш бирү тәмамланган мизгелгә референдумда катнашучылар исемлекләренә 602 катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучылар саны - 553, бу муниципаль берәмлек территориясендә референдумда катнашучылар исемлекләренә кертелгән референдумда катнашучыларның 91,86 процентын тәшкил итә

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

тавыш бирүдә катнашкан 492 катнашучы «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде, бу тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучыларның 88,97 процентын тәшкил итә;

«Юк» позициясе өчен референдумда **57** катнашучы тавыш бирде, бу **10, 31 %**. тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Теләче районының территория сайлау комиссиясе (ИКМО) карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Шәдке авыл җирлеге территориясендә референдум узган, референдум нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. Әлеге сорау буенча карарны:«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәдке авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2018 елда 500 сум күләмендә гражданнарның үзара салымын кертүгә сез ризамы, алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юллап:

**1.1.Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны да кертеп):**

- әлеге торак пунктларда урамнарны яктырту:Шәтке, Олы Мирәтәк, Югары Мирәтәк (энергияне сак тотучы лампаларны, энергияне исәпкә алу приборларын сатып алу һәм урнаштыру);

- Югары Мирәтәк ав.1941-1945 елларда Бөек Ватан сугышында Җиңү хөрмәтенә куелган һәйкәлне төзекләндерү.

**1.2.Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

-Шәдке, Олы Мирәтәк, Югары Мирәтәк ав. күперләрне төзекләндерү, юлларны төзекләндерү, юлларны кардан чистарту, юлларны чүп-чардан чистарту, юл буйларында үлән чаптыру, вак таш сатып алу һәм ташу.

**1.3. Халыкны су белән тәэмин итүне җирлек чикләрендә оештыру:**

-Шәдке авылы чишмәсен төзекләндерү, Шәдке, Олы Мирәтәк, Югары Мирәтәк ав. скважиналарны санитар саклау зоналарын төзекләндерү.

**1.4.Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:**

- янгын автоцистернасын тоту» кабул ителгән дип санарга.

3. «Теләче» район газетасында җирле референдум нәтиҗәләрен бастырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Теләче районының рәсми сайтында урнаштырырга.http://pandia.ru/text/category/informatcionnie_seti/

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Шәдке авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Комиссия рәисе Р.Н. Яруллин

Комиссия сәркатибе А. В. Гыйниятуллина